**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы** Мәләкәс **авыл җирлеге составына керүче Куаклы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

10 ноябрь, 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 10 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 16 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 16 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 16 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы

Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Р.В.Иванов